РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Нижнекамский муниципальный район
СОВЕТ
муниципального образования
«пгт Камские Поляны»

423564, «пгт Камские Поляны», д.4/04,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
«штп Кама Аланы»
муниципаль бәремлеге
СОВЕТЫ

423564, «штп Кама Аланы», 4/04 йорт,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

Карар

2024 елның 11 июнь № 9

«Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Советы ЧИШҮ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Кама Аланы штп муниципаль
берәмлеге башлыгы Р. Р. Салахутдинов